Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ НОЯБРЬ * 2021 * КАЗАН

11



Анатолий НЫРОВ

Теманың дәвамы – 16-17 нче биттә.

Рашат НИЗАМИ

АЮ МАҖАРАСЫ

(мәсәл)

Иялəшкән аю бер чүнниккә,
Килә икән төнлә шым гына.
Балы белән тулган яшь кәрәзне
Ялмап китә икән тын гына.

Урманчы карт хәйлә корган әнә:
Уйлап тапкан җәза аңарга, –
Тагаракка баллы көмешкәне
Коеп салган тәмләп яларга.

Килгән аю. Кызыксынып китеп,
Яңа "сый"дан авыз иткән бит.
Күрче: ялмап-ялмап йоткан саен
Күңелле вә рәхәт икән бит!

"Баллы" суның төбен ялтыраткан,
Бушап калган агач тагарак.
Фәлән-фәлән вакыт үтте микән –
Аю ята җирдә тәгәрәп.

Фатих Кәрим* сөйләгәнчә итеп,
Гармун тотып җырлап йөрмәгән.
Тирә-юньдә, "тыз-быз-з" дигән көйгә,
Бал кортлары бары гөжләгән.

Гырлый-гырлый мәрткә киткән аю, –
Көмешкә бит башка сикергән!
Ау мылтыгын читкә ташлаган карт,
Килгән гуманистик фикергә.

Дүрт тәпиен чорнаган бау белән,
Авызына – ныклы борындык.
Аю белән ни кылырга хәзер?..
Зоопаркка таба борылдык.

Әйе, әйе, шәһәр читендәге
Зоопаркка илтеп тапшырган.
Иртәгесен аю әфәндебез
"Мин кайда?.." – дип, байтак кашынган.

"Чыгарыгыз мине иреккә!" – дип,
Аю мескен байтак ялына.
...Шулайрак тәмамлана хәлләр,
Күз төшерсәң кеше малына!

Алмаз ХӘМЗИН

Озак ятмас Аю читлегендә,
Аның өчен дөнья – карнавал!
Зоопарк – бункер, шәп ял йорты,
Ә без бал кортлары – корбаннар!..

* *Фатих Карим – "Гармунчы аю белән җырчы маймыл" әкиятенең авторы.*

Николай ВОРОНЦОВ



ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Бу болганчык заманда төрле күрәзәчеләр, сихерче-шаманнар һәм «җен карчыклары» үрчеп китте. Алай гына да түгел, алар өчен телевидениедә «тылсымчылар каналы» булдырылды. Магия әһелләре анда халык алдында киләчәкне фаразлыйлар, сихерлиләр һәм башка хикмәтләр күрсәтәләр. Бушлай түгел, әлбәттә. Гаҗәп хәл – безнең белемле илдә шушы әкиятләргә ышанучылар бар бит...

М. ӘХМӘДИЕВ

Әлмәт

– **Ә иң мөһиме шул – 2013 елда бер тылсымчының да бүген кыйммәтләнеп баручы биткоин сатып алмавы гаҗәпләндерми. Шуңа да карамастан, алар һаман сихерләре белән кеше башы катыралар,** – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

ӨЛКӘН ИТЕП ТОЯМ...

Балачактан калган саф гаделлек
Билəп тора һаман күңелне.
Тамак кырып, җитди сөйләшкәндә
Ялганчы күк тоям үземне.


Күзләренә карап кабахәтнең,
Килә барысын әйтеп бирәсе:
Фәлән абзый, синең кара җаның
Күзләреңә чыккан, диясе;

Очратканда шундый мәлгуньнәрне,
Булса да ул шәһәр түрәсе –
Күпләп акыл сатып тормый гына,
Чыраена менеп төшәсе;
Зур каракны тотып кулларыннан
Бар дөньяга шәрран ярасы,
Җилтерәтеп тотып җилкәсеннән,
Прокурорга алып барасы;
Тузган бишмәт кигән карт әбине
Хәер сорап торган чагында,
Алып китеп аны, күрсәтергә
Госдуманың утырышында;
һәм сорарга: әй сез, тук абзыйлар,
Илебезнең эшчән атлары,
Биргән вәгъдәләрне үтәвегез
Шулмы, халык депутатлары?

Ләкин ялган һәм хаксызлык күрсәм,
Читкә борам никтер йөземне.
Чөнки күптән малай-шалай түгел –
Өлкән итеп тоям үземне...

Ринат АБЗАЛОВ

Александр ЛЕВИТИН





Александр АЛЁШИН



Паника

Нәрсә ул паника? Ул – самолёт моторының тавышы чак-чак үзгәргәч, салонда "Баш бетте!" дигән зәһәр аваз. Ул – кибет киштәләреннән шикәр һәм карабодай ярмасын кырып-себереп алучы кырыс хатыннар. Ул – тыныч кына юлга чыгу урынына, кечкенә каенлыкта адашып, чабып йөргән гөмбә җыючы. Хуҗасын югалтып, урамнар буенча чабып йөрүче эт тә – паника мисалы...

Ә менә батып баручы "Титаник"та паника башта булмаган. Палубада оркестр уйнап торган, барысы да бер-берсенә көймәләрдә урын биргәннәр, корабльне ташлап китәргә беркем дә ашыкмаган... Паника "Титаник" кыйгайгач кына башланган. Менә шунда инде этеш-төртеш башланган, кешеләр акылларын җуеп, бер-берсенә көймәләргә утәргә комачаулый башлаган. Нәтиҗәдә, пассажирлар һәм экипажның яртысыннан ким өлеше генә исән калган. Хәтта Ди Каприо да салкыннан аңын югалтып, батып үлгән...

Шулай да, файдалымы, әллә зыянлымы паника дигәннәре? Психологлар уртак фикергә килә алмыйлар, тик шулай да халык күп җыелган урында аны куркыныч дип саныйлар. Юкка гына сугыш вакытында паникага бирелгән кешеләрне ата торган булганнар бит. Кызганыч, хәзер мондый нәрсә тыелган...

Дөньяга паника өчен иң үтемле сәбәп – коронавирус бүләк иткән кытайлар күптән түгел паникага каршы юнәлтелгән уенчык сата башлаган. Ул бөтенебезгә дә таныш: шартлый торган төмгәкле полиэтиленга охшаш нәрсә. Бөтен сыйныфташлары кебек үк, ул нәрсәне кызым да сатып алды. БДИ алдыннан паникага бирешмәс өчен. Минем үземнең дә холкым бик тыныч түгел, шуңа күрә футбол барган чакта аны кызымнан алып торам. һәм Россиянең җыелма командасы үзенең "Иң мөһиме җиңү түгел, ә катнашу" шигаре астында уйнаган чакта мин ашыкмыйча кына төмгәкләр шартлатып утырам. Җаным, безнең футболчыларныкы кебек, тып-тыныч. һәм мин шунда, галим булмасам да, фәнни ачыш ясадым. Ул менә нәрсәдән гыйбарәт:

Паникадан өч әйбер коткара ала. Җиңел паникадан (таксида, поездда, хатын өйдә булу, "Почта России" һ. б.) әлеге дә баягы Кытай уенчыгы саклап кала. "Бандеролегез ертылган, эчендәге әйберләр югалган", – ди почта хезмәткәре. Сез, елмаеп, төмгәкләр шартлатасыз, почта начальнигын чакыру башыгызга да килми... Катлаулырак очрак – самолёт чайкала башлый, туктап калган караңгы лифт, космик станциядә кислород кимү. Бу очракта иң хәерлесе – сулышны туктатып, күңелдән иске әйтемнәрне кабатлау. Иң куркыныч очрак – нефть бәясе төшү, ачлык якынлашу, хатының ташлап китү һәм начар авыру белән бәйле паника. Башыгызда бары тик ике уй: "Ничек яшәргә һәм яшәүнең кирәге бармы?" Бу уйларны читкә куыгыз! Чын паниканың бердәнбер гәүдәләнеше бар – ул да булса рәссам Мункның атаклы "Кычкыру" картинасы. Шул картинаны сатып аласыз (оригиналын, әлбәттә), стенага элеп куясыз – паника юкка чыга. Хатыныгыз киттеме? Суыткычта кара икра юкмы? Коронавирус белән авырып киттегезме? Ахыр заман якынлашамы? Онытыгыз бу турыда – сезнең стенагызда 120 миллион доллар асылынып тора! Яшь хатын аласыз, иң сыйфатлы икрага заказ бирәсез, иң шәп табибларны чакырасыз, ә ахыр заман үзе кире борылып китә. Картинага карадыгыз, коттеджыгызның балконына чыгып утырдыгыз, бокалга иң затлы виски салдыгыз – һәм Урта диңгезнең назлы дулкыннарына карап соклanasыз. Ә ул арада табиблар да килеп җитә, икра да китерәләр. Нинди паника булсын монда?

Ә үлүен барысы да үләчәк, кайсыдыр иртәрәк, кайсыдыр соңрак... Кемдер коммуналь фатирында иске шыгырдавык караватта, ә кемдер Мунк картинасы астында – крокодил тиресе белән тышланган диван өстендә. Бер аермасы да юк...

Ә паникага бирелүнең нигә кирәге бар?

Илья КРИШТУЛ





Валерий ТАРАСЕНКО



Илдар НӘФИЕВ



• • •

Табиб – пациентка:

– Сез бик тәртипсез авырту булып чыктыгыз бит әле. Урыныгызда ятмыйсыз, даруларны эчмисез, укол кадатмыйсыз. Җитмәсә, үзегезне көннән-көн яхшырак хис итәсез.

• • •

Сайлауларны беркайчан да калдырмыйча йөрим: регистрациядә минем фатирга арендаторларны пропискага кертмәделәр микән дип тикшерәм.

• • •

Мәктәпкә фотограф килгән. Укытучы укучыларын фотога төшәргә үгетли:

– Күз алдыгызга китерәсезме – зур яшькә җиткәч, фотога карарсыз да әйтерсез: "Менә бу – Сәлимә, ул хәзер күренекле артистка. Ә менә монысы – Әхмәт, ул инде атаклы табиб булды..." – дип.

Шул вакыт иң арткы партадагы Җәүдәт:

– Ә менә бу сез, Җәмилә Рәүфовна, урыны җәннәттә булсын, ул инде күптән үлде, диячәкбез.

• • •

Эшлисе эшләрегезне бүген үк эшләгез, иртәгә калдырмагыз. Соң булуы мөмкин, иртәгә ул эшне тыюлары мөмкин.

• • •

Поезд купесында бер ир, онытылып, янәшәсендә утырган кызны күзли. Ниһаять кыз, смартфоныннан аерылып, сүз башлый:

– Өйләнгән күзләрегез белән миңа шулай карап утырырга кирәкми!

• • •

Ир – кызга:

– Әлегә мин сезгә өйләнергә әзер түгел, әмма ирлек вазыйфасын хәзердән үк әкренләп үти башларга риза.

• • •

– Безнең җитәкчебез нишләп шулай тупас шаярта? Югыйсә юмор хисе бик шәп бит аның!

– Ул ялагайларны ачыклый!



Ринат АБЗАЛОВ

МАКСАТ

Максат куйдым.
Зур һәм бик кыюны,
һәм матурны – менә, карагыз;
Кояшсыз киң дөнья булмаган кук,
Яши алмый кеше максатсыз!

Олуг планнарым билгесен мин
Бизәкләп һәм сырлап эшләдем;
Ныклык өчен биек постаментны
Затлы гранит белән тышладым.

Ошбу максат минем тормышымны
Киләчәгем белән бәйләде.
Мәңге торыр хәзер зур юлымда
Минем көчле рухым һәйкәле!

• • •


– Миңа кияүгә чыгасыңмы?
– Мин риза, – ди кыз.
Тынлык урнаша. Ниһаять кыз түзми:
– Нигә бүтән бер сүз дә әйтмисең, кадерлем?
– Болай да артыгын ычкындырдым инде, – дип җавап бирә егет.

Валентин ДРУЖИНИН





Александр ШУЛЬПИНОВ





Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

ПАНДЕМИЯ

Пандемия...

Шул пандемия башлану белән гаиләбезнең асты өскә килде. Инде картым белән култыклашып урамга чыгулар да бетте. Кая чыгасың? Икебезгә бер битлек. Беребез чыкса, икенчебез өйдә утыра. Аннары аны юабыз, киптерәбез дә, тагын кияргә була. Ә ничек башкача? Пенсиябезгә ашаргамы, әллә битлек сатып алыргамы? Әле, җитмәсә, теге ЖКХ дигән нәрсә дә бәяләрне күтәреп тора. Шулай булгач, парлашып йөрикмени?..

Бер көнне сүз чыкты, картларга вакцина ясатырга кирәк икән.

– Карчык, син бүген бар, мин икенче көнгә калырмын, – ди миңа картым.

– Ярар, – мин әйтәм, – хәзер җыенам да китәм.

Җыена башлагач карасам, битлегебез таралып төшкән. Менә сиңа мә. Икенче ел киябез бит. Нишләргә инде?

– Поликлиникада бирерләр әле, – ди картым.

Бардым инде, поликлиникага ышанып. Анда керүем булды, ишек төбендә туктаттылар:

– Әби, кая битлексез керәсең?

– Ник, сездә бирмиләрмени аны? Бахилы дигән нәрсәне бирәсез бит.

– Сезгә барысын да бирә башласаң, йә чыкмассыз моннан. Якында гына дарухanә бар, шуннан сатып алыгыз.

Киттем әбына-сөртенә дарухanәгә. Ишеген ачсам, миңа:

– Әби, кая керәсең битлексез? Битлексез керү тыела!

– Соң, – мин әйтәм, – шул битлек сатып алырга килдем бит инде!

– Битлек сатып алыр өчен дә битлектән керергә кирәк!

– Битлегем булса, сорар идемме мин сездән?

Кире әйләнеп өйгә кайтырга туры килде.

– Ничек, кадаттыңмы вакцинаны, – ди картым.

– Юк, булмады. Кертмәделәр.

– Ничек? Үзләре чакырдылар бит.

– Чакыру белән генә булмый икән шул. Дарухanәгә кереп алмакчы идем, анда да кертмәделәр. Шуңа күрә кире әйләнеп кайттым.

– Карчык, хәзер нишлибез соң инде?

Шунда минем башыма бер уй килде:

– Карале, безнең бит үлемтеккә дигән марля ята түгелме?

– Нишләтмәкче буласың аны? – дип, картым аптырап калды.

– Нишләтмәкчеме? Ә менә хәзер күрерсең, – дидем дә, борынгы сандыгыбыздан шул марляны чыгардым.

Аннары аны кисәкләргә бүлеп, якъякларыннан баулар тегеп, битлек ясадым. Күп битлек килеп чыкты.

– Әй, уңган да инде син карчыгым! – дип мактап куйды мине картым. – Болай булгач, без тагын икәүләшеп йөри алабыз бит урамда. Ничек элек башыңа килмәгән ул уй?

– Менә, килеп терәлгәч, җае табылды.

– Тик менә икенче уй борчый мине хәзер...

– Нинди?

– Без бит аны үлемтеккә дип алып куйган идек.

– Ул безгә хәзер кирәк булыр диеп уйлыйсыңмы? Вакцина ясаткач!.. Яшиселәр бар әле!



ЭШЛӘҮДӘН ТУКТАГАН

Октябрьдә Бөгелмәдә иҗтимагый транспорт эшләүдән тулысынча туктаган. Бердәнбер транспортчы – 8 шәһәр маршрутына хезмәт күрсәткән шәхси эшмәкәр Минаевны прокуратура тикшерә. Исполком аның белән төзелгән килешүне вакытыннан алда гамәлдән чыгарган. Шунысы кызыклы, Бөгелмәдә транспорт тарифы 2016 елдан 2021 елга кадәр үзгәрмәгән һәм 18 сум тәшкил иткән. Казанда моның өчен минаевчыларга рәхмәтле пассажирлардан медаль тапшырырлар иде!

ТҮЛӘҮЛЕ ХЕЗМӘТ

Мәскәүдә Дәүләт Думасының экология буенча элеккеге башлыгы – танылган галим Владимир Грачёв ришвәт алганда капкан. Тикшерүчеләр фикеренчә, ул «РТ-Инвест» компаниясенә Мәскәү янында һәм Татарстанда чүп яндыру заводлары төзүдә булышлык күрсәтергә сүз биргән. Үзенең күрсәтеләчәк хезмәтен элеккеге башлык 1 миллион еврога бәяләгән. Галимне сумманың беренче өлешен – 3 миллион сум алган чакта тоткарлаганнар.

КЫЙММӘТЛЕ БРАК

Чаллыда 1997 елда чыгарылган 5 сумлык металл таңкәне 250 миллион сумга сатарга җыеналар. Сатучы ул таңкәне составында чит металл бөртекләре булу сәбәпле, сирәк "брак" дип белдерә. Ул "раритет" коллекционерлар арасында кызыксыну уятыр, йә затлы бүләк сыйфатында сатып алыныр дип өметләнә. Әйтергә кирәк: узган ел автошәһәрдә 5 тиенлек металл таңкә 5 миллиард сумга сатуга куелган булган.

ЙОКЫ ӨЧЕН ҖӘЗА

Кукмарада 51 яшьлек ирне чит кеше йортында йоклаган өчен хөкемгә тартканнар. Яңа Каенсар авылында яшәүче берәү исерек килеш авылдаш хатынының йортына хәмер эзләп кергән. Эзләнеп, кирәк нәрсәсен тапмагач, ял итеп алырга булган. Ярты сәгать черем итеп алганнан соң, ул йорттан чыгып киткән. Хәзер аны "Торак кагылгысызлыгын бозу" статьясы буенча җәза көтә.



Берәү СИЗОга килә һәм берничә көн элек үзенең фатирын баскан карак белән очраштыруны үтенә.

Сакчы:

– Ник кирәк ул сезгә, судта барыбер күрешәчәксез бит!

Тегесе:

– Беләсезме, әгәр дә ул миңа төнлә хатынны уятмыйча фатирга ничек кергәнен сөйләсә, аңа гаризамны кире алам дип әйтергә телим...

Игорь КИЙКО



Вячеслав ШИЛОВ



Николай ВОРОНЦОВ



РЕЛЬС КАРАКЛАРЫ

Чехов хикәясе персонажы тимер юлда гайкалар борып чыгарган. Ул моны усал ният белән эшләмәгән – гайкалар аңа кармак батыргычы сыйфатында кирәк булган. Шуңа күрә беркатлы ир заты чын күңеленнән гаҗәпләнгән – аны нәрсә өчен тинтерәтәләр соң?

Бүгенге караклар киң колач белән эшли. Аларга гайка гына җитми – аларга рельслар кирәк! Мәсәлән, Актүбә бистәсеннән өч бәндә тимер юлдан рельс чәлгәннәр. Табышны алар 7 мең сумга металлоломга тапшырганнар. Сәүдә гамәле сизелмичә калмаган. Тикшерүчеләр аларның мондый эш белән беренче тапкыр гына шөгыльләнмәвен ачыклаганнар. Хөкем карары укылганда, Чехов героеннан аермалы буларак, аларның башында «Нәрсә өчен?» дигән сорау туарга тиеш түгелдер...

КРИМИНАЛЬ ФИКЕРЛӘР

- Гаҗәеп хәл: бөтен телевизор каналларында атышүтереш, ә халык – тотрыклылык өчен.
- Ахмак караклар полиция беркетмәләренә эләгә, ә акыллылары – Форбс исемлегенә.
- Бездә шундый шәп законнар ки, алар белән файдаланыр өчен түләргә кирәк.
- Француз сырларын илгә кертү нигә тыела, ә французларның радиоактив калдыкларын кертергә ярый?
- Иң житез хезмәт булып ритуаль хезмәте күрсәтү танылган.
- Безнең төрмәләр юньләп җинаять кылмый-торган кешеләр белән тулган.



НЫКЛЫКНЫ СЫНАУ

Кадерле "Чаян"! Шаккаткыч кызык карарга яратучылар, әллә кайларга барып күңелләрен ачарга, хәтта җир тишегенә керергә әзерләр. Югыйсә мондый җирләр үзебезнең якларда, янәшәбездә дә бар бит.

Шундый бер урын Юдинодагы Күзембәт урамында гына. Бу күпер шундый кызганыч хәлдә ки, аның өстеннән җәяү чыгарга да куркыныч. Кая анда машина белән үтү!.. Терәкләре авышкан, яр кырыйларын ныгыткан бетон калдыклары ишелгән – күпкә чыдамас, ишелер, мөгаен, күпер! Кызык табасы килгән кешегә бар монда хикмәт!

Әмма бистәдә андыйлар чалынмады. Югыйсә монда яшәүчеләр инде ничә еллар буе төрле хакимият ишекләрен шакып йөрде, шушы күперне ремонтлау мәсьәләсендә. Иң элек 2020 елны вәгъдә бирделәр, ләкин үтәлмәделәр, финанслау чаралары "икътисадта кризис" булу сәбәпле, Казан бюджетында калган. Шуңа күрә күпернең чыдамлыгы 2022 елга кадәр озайтылган. Шулай итеп кешеләрнең түземлелеген дә сыныйлар микән?..

И. БУРУНИ

ЮДИНО бистәсе, КАЗАН

ТӘРБИЯВИ НӘТИҖӘ

"Чаян" дус! Соңгы вакытларда Чаллы шәһәрендәге балалар бакчаларында эшләүчеләргә кытлык була башлады. Тәрбиячеләр эштән китә, бу юнәлештәге һөнәрчеләр һәм бала караучылар да... Яшьләр мәктәпкәчә белем алырга бик ашкынып тормый югыйсә Чаллыда институт та, педколледж да, янәшәдә – Алабугада growth педининститут та бар. Төп сәбәп, мөгаен, хезмәт хакының түбән булуындадыр... Югары белемле тәрбиячеләрнеке дә 20–25 мең генә, ә бала караучыларныкы бары тик – 15 мең...

Эш монда гына түгел. Кытыклыкның тагын бер ягын әйтеп үтәргә кирәк: бу хәзерге әтиәниләрнең "белдекле" буыны аркасында да. Артык актив әниләр һәм әтиләр кайвакытта тәрбиячеләргә яла ягу, басым ясау белән мавыгалар. Балага тияргә ярамый, сорау һәм таләп итүләр дә, инде кисәтеп тавыш күтәребрәк эндәшү дә начарлык дип исәпләнә... Баланың арт ягына "чәп" итү – монысы аның тормышына куркыныч яный дигән сүз. Прокуратурага, полициягә, Европа судына һәм башка инстанцияләргә мөрәҗәгать итү белән яный башлыйлар. Мондый конфликтлы очракларда җәмәгать фикере, нигәдер, һәрвакыт алар ягына авышкан була...

И. Р-ва, Балалар бакчасы тәрбиячесе.

ЧАЛЛЫ

Илдар НӘФИЕВ



Нәҗибә САФИНА

ЯКТЫ ЭЗЛӘҮ

Төнге сәяхәттә йөреп кердем,
Бу күзгә төн шундый кара икән,
Сәяхәттә, күңел анда да тик
Бары якты эзләп бара икән.

Яктыртырга вәгъдә бирә-бирә,
Мөнбәрләргә менгән депутатлар
Тигәнәкләр баскан сукмакларны
Әллә безнең кебек дисең, таптар?

Алар инде җәяү атламыйлар,
Һәммәсе дә чит ил автосында.
Ишекләрендә генә дә түгел,
Тимер йозак биек капкасында.

Вәгъдәсенә тугры – төнге бер ай,
Көнен кояш кына яктыртучы.
Депутатлар әйбәттер әйбәтен,
Иблис начар, һаман котыртучы.

Сукмак түгел, юлдан язмас өчен,
Таяк белән төртеп-төртеп барам.
Мөнбәрләрдән биргән вәгъдәләрен
Үтәмәгәннәргә ризык хәрам!

Иблис бела, әнә, бер "Мерседес"
Юлсыз юлның пычрак суы белән
Коендырып китте, мәлгун, мәлгун! –
Автономерыннан танып калдым.

Юктыр димә, ялгыш күргәнсеңдер...
Хәтер начар диеп, мин бит аның
Фотосын да, биргән вәгъдәсен дә,
Автономерын да язып алдым...

Хәзер әйтер идем фамилиясен,
Пычрак су астыннан чыга алмыйм...



Вячеслав ШИЛОВ



Александр ЛЕВИТИН

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

- Дөреслек табуга караганда, хата табу җиңелрәк.
- Кешеләр булмаган урында да кеше булып калырга кирәк.
- Зирәклек чыганагы – тәҗрибә. Тәҗрибә чыганагы – акылсызлык.
- Чын ялгызлыкны зур шәһәрдә генә табып була.
- Әгәр дә ике кеше уртак фикер таптап кан икән, димәк, аларның берсе генә уйлый.
- Кешеләр картаялар, ләкин олыгаймыйлар.
- Ялагайлану – кешегә үзе турында уйлаган әйберне әйтеп бирү.
- Олы яшьтәге кеше өчен яшьлек – иң зур җитешсезлек.

(Тормыш белгечләре мәҗлесендә язып алынды)

Василий АЛЕКСАНДРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Виктор ФЁДОРОВ



Антон МАКУНИ

Склероз

Соңгы вакытта башыма әллә нәрсә булды – бөтен нәрсәне оныта башладым. Бернәрсә дә хәтерләмим. Дөресрәге, нәрсәнедер хәтерлим, нәрсәнедер – юк.

Менә кичә исемдә – аванс алдым. Билгеләргә булдым. Ә калганы – кисеп аттыларммыни! Кайда, кем белән, күпме һәм нәрсә – юк инде, истә түгел! Аванс алганым истә, ә хәзер аның ник булмаганын әйтә алмыйм!

Ә эштә бөтенләй акылдан язарлык! Киләм, утырам, ә нишләргә кирәген – хәтерләмим. Бераздан кылт итеп әбәткә барырга кирәклеге искә төшә. Әбәттән киләм – тагын бушлык! Утырам, газапланып искә төшерергә тырышам... Инде хәтердә нәрсәдер кыймылдый гына башлый – шалт, эш көне бетте!

Гаилә тормышында да шул ук нәрсә. Хатын гел зарлана: имеш, бар нәрсәне онытам – йә хезмәт хакын кайтарып бирергә, йә чүпне чыгарып түгәргә. Билләһи дим, ялган бу! Ирлек бурычы турында беркайчан да онытмыйм. Төн уртасында уят – пажалысты! Үзем өчен дә, башкалар өчен дә үти алам.

Ә-ә-ә, бурычлар турында. Аларны да онытам шул. Бөтенесен дә түгел, әлбәттә. Үзем бирсәм, гомерем буе истә тотам, ә алсам – бер секундтан баштан чыга!

Күптән түгел табибта булдым – нинди икәнен хәтерләмим. Ул миңа кулъяулык почмагына төеннәр бәйләргә киңәш итте. "Карчыкларга да ярдәм итә", – ди. Кичтән төеннәр бәйләп куйдым: берсе – чүп чыгарырга, икенчесе – эштә отчётны тәмамларга, өченчесе – хатынга бүләк алырга. Иртән карап утырам төеннәргә – берни хәтерләмим!

Көне буе эш урынына шул төеннәр белән мәш килеп утырдым. Файдасыз! Кичкә таба гына искә төшә башлады: беренче төен – сыра эчеп чыгарга, икенчесе – телевизордан футбол карарга, ә өченчесе, әлбәттә, ирлек бурычын үтәргә. Ярдәм итә, димәк! Белсәгез, ничек шатланганымны! Дөрес, ул кулъяулыкны кайдадыр онытып калдыргканмын. Төеннәре белән бергә. Кыскасы, буш сүз бу!

Аптырагач, киттем экстрасенска. Халык медицинасы – вәт, ичмасам, фән! Ике сәгать буе әфсен-төфсен ясады бу. "Әбизәтелне ярдәм итәчәк", – ди.

Кая ди ул?! Ярдәм итмәде! Чөнки сеанстан соң мин аңа акча бирергә онытканмын. Гонорар сорап, арттан ярты чакрым чапты. Нинди гонорар, мин аның чыраен хәтерләмим бит! Картаям, күрәсең... Алай дисәң, утыз җиде генә тулды бит әле. Әллә утыз сигезме? Тфү, тагын онытканмын! Өстәвенә, хатын нәрсәдер кушкан иде бугай... Карале, хәтердән чыккан бит, шайтан... Ә-ә-ә, искә төште! Бүген бит телевизордан футбол була! Онытканчы өйгә чабарга кирәк!

Абау!

ТЕЛСЕЗЛӘР ФРАКЦИЯСЕ

Яңа Дәүләт Думасына узган чакырылыш утырышларында бер тапкыр да чыгыш ясамаган 20 депутат кергән. Аларның 17 се – «Бердәм Россия» вәкилләре, икесе – КПРФ һәм берсе ЛДПР партияләреннән. Дәшмәүчеләр арасында Мәскәүнең элеккеге вице-мэры Владимир Ресин, 2020 ел өчен шәхси керемнәр буенча лидер Григорий Аникеев, полярник Артур Чилингаров һәм авызына су капкан башка хезмәткәрләр бар.

ТАВЫШ БӘЯСЕ

Приморье краенда Славянск шәһәр җирлеге депутатын башка депутатка ришвәт бирүдә шикләнәләр. Сайлаулардан соң халык ышанычлысы үзен рәис итеп күрүләрен теләгән һәм эшне майлау максаты белән шул ук җирлектәге коллегасына аның файдасына тавыш бирсен өчен, 500 мең сум акча тәкъдим иткән. Килешү төзелгән, әмма оперативниклар контроле астында.


БОРЧУГА САЛГАН

Чиләбе өлкәсенең Миасс шәһәрендә тиз туклану кафесы гадәти булмаган акция игълан иткән. «Икеле» алган өчен укучыларга бушлай шаурма ашатканнар. Мондый педагогика кануннарына туры килмәгән маркетинг юлы «икеле капчыклары»ның ата-аналарын борчуга салган. «Укымасаң да була, барыбер тук буласың диган мотивация дөрес түгел!» – дип белдергән алар. Кафе, «икеле капчыклары» барыбер әти-әниләреннән тукмак аласыларын белеп, аларга мораль яктан ярдәм итәргә теләүләре белән акланган.

АЛ ДА КАЧ!

Дания рәссам-концептуалисты Йенс Хаанинг заманча сәнгать музееннан 534 мең крон (6 миллион сумга якын) акча шудырткан. Акча аңа күргәзмә эше булдыру өчен кирәк булган. Композиция акча тутырылган ике пыяла тартмадан торган, Дания һәм Австриянең гражданнарының еллык керемен чагылдырырга тиеш булган. Тик композицияне музейга китергәч, тартмалар буш булып чыга, ә эш «акчаны ал һәм кач» дип үзгәртелгән. Рәссам. эшләгән эшен сәнгать әсәре дип акланып, акчаны кире кайтарудан баш тарткан.

Сергей АНДРИАНОВ



Игорь КИЙКО



Мирзаһит тормышыннан

ПРИКАЗ

Яңа ферма мөдире Агабәков беркемнең дә күңеленә хуш килми. Яшь, тәкәббер, өстәвенә, әле чиктән тыш комсыз да. Беренче айда ук бөтен эшчеләрнең хезмәт хакын кисә, имеш, ниндидер элекке план үтәлмичә калган икән. Эш кирәк-яракларында экономия ясый, эштән соң тоткарланырга мәҗбүр итә, өлкәннәрне ихтирам итми...

Берзаман ул хезмәткәрләрне ферма янында җыя һәм хәбәр итә:

– Менә нәрсә! Беренче корпус янына печән китерделәр – аны чормага менгезеп куярга кирәк. Димәк, бишкә кадәр түгел, ә планны тулысынча үтәгәнче эшлибез: һәркемнең кулы аша 3 тонна печән үтәргә тиеш! Бөтенегез алдында әйтәм, хәйләләп йөрүчеләр булмасын. Алайса акчасыз каласыз!

– Болай бит без төнгә кадәр дә эшләп бетерә алмаячакбыз! – ди Вәли.

– Ә сез әзрәк сөйләшегез, күбрәк эшләгез! – ди дорфаланып Агабәков. – Хәзер мин шәһәргә китәм. Иртән кайту белән килеп тикшерермен.

Аның сүзләрен җөпләгәндәй, абзардан ямьсез дуңгыз мыркылдавы ишетелә.

Мөдир китеп бара, ә халык, күңелсезләнеп, сәнәк алырга тарала.

Шунда Мирзаһит чикән чыккан начальникне акылга утыртырга була. Бераз уйлагач, шәп фикергә килә! План бик гади иде: берәмләп эшләргә түгел, ә рәткә тезелеп, печәнне бер-береңә биреп торырга. Нәтиҗәдә, берничә сәгать эчендә куелган планны үтиләр дә.

Иртүк Агабәков тикшерергә килеп җитә. Корпус янында калган печән өемен күреп, ул чыгырыннан чыга.

– Нәрсә, ялкаулар, приказны үтәмисез? Зарплатасыз калырга телисезме? – дип җикерә ул эшчеләргә.

– Тукта, начальник, син кайнама әле, – ди Мирзаһит, алга чыгып. – Кичә бит син үзең әйттең: һәр кеше аша 3 тонна печән үтәргә тиеш дип. Без шулай иттек тә. Тик син бит һәркемнең дә үзенең өч тоннасы булырга тиеш дип әйтмәдең. Шуңа күрә без рәткә тезелеп, печәнне бер-беребезгә биреп тордык һәм синең приказыңны үтәдек!

Агабәков кызарына, иренен тешли, ләкин әйтергә сүз таба алмый.

КИЯҮНЕҢ ИСЕМЕ

Авылның беренче чибәре Нәфисә көн саен диярлек егетләрне алыштыра. Бер кич әти-әнисен үзен озатып куйган егет белән таныштыра: «Бу – Флорис, минем егетем». Бер атнадан кызының телефоннан сөйләшкәнен күреп:

– Флориска сәлам әйт! – ди.

Кызы гаҗәпләнеп:

– Әни, нинди Флорис? Бу Артур бит, – ди.

Әнисе тирән сулап кына куя. «Бөтенесен дә истә тотып буламыни аларның?»

Нәфисәнең әтисе кызы турында сораштыра башлагач, болай җавап бирә иде:

– Тормыш юлдашын табу җиңел нәрсә түгел шул. Бу сезгә карбыз сайлау түгел! Монда баш белән уйларга кирәк...


Ниһаять чибәркәйнең ярсу йөрәген яулап алган егет табыла. Эш туйга барып җитә, анда хатыны белән Мирзаһитны да чакыралар.

Билгеләнгән көнне Мирзаһитның хатыны яшьләр өчен котлау открыткасы язарга утыра.

– «Кадерле Фаяз һәм Нәфисә...» дип язам. Кияүнең исеме шулай бит?

– Син аның исеме белән ашыкма әле, – ди аңа Мирзаһит. – Барып җитик әле, шунда язарсың... Бу кызыйдан нәрсә көтәргә икәнен белеп булмый!

Зөлфәт ШАҺИӘХМӘТОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Эрнест ДЫШАЕВ



• • •

Фирма хезмәткәре директор кабинетына керә.

– Мин үзем сорарга батырчылык итмәс идем, әмма хатын акчамны арттырсыннар диде бит әле.

Директор телефонын ала һәм каядыр шалтырата. Аннан, трубканы куеп:

– Нишләтергә инде бу хатыннарны?.. Минеке «Юк!» – диде!

Виталий ФЕОКТИСТОВ



ХӘРБИ ХЕЗМӘТ

Без гаиләдә биш ир бала үстек, шуларның бишесе дә солдат. Хәзер генә ул, альтернатив хезмәт дип армиядән качып, хастаханәдә тас-чиләк ташып йөриләр. Оялмыйча. "Бәлки, мин хаталанамдыр, анысы да эш, анысы да хезмәт. Ләкин мин аның хәрбилеген, хәрби хезмәт икәнен күрмим, аңлап җиткермимдер", – дип язган идем "Консерватория Армия Филармония" исемле китабымда. Андый гаиләләр, бәлки, тагын бардыр. Ләкин иң мөһиме һәм иң кызыгы шунда – без өч Сатиев, өч бертуган бер гаиләдән бер вакытта, берьюлы Совет Армиясендә хезмәт иттек: Кирам – 12 ноябрь 1979 ел чакырылу, 18 май 1981 елда кайту. Хезмәт иткән урыным Саратов (Сарытау) өлкәсе, Вольск шәһәре. Энеләрем – Мансур: 12 ноябрь 1978 ел – 23 декабрь 1980 ел. Мәскәү өлкәсе, Серпухов шәһәре; Хәсән: 30 октябрь 1980 ел – 26 ноябрь 1982 ел. Бурят АССР, Кяхта шәһәре. Әйткәнемчә, өч "брат"ның бер үк вакытта, берьюлы армиядә хезмәт иткән тагын шундый гаилә бар микән?! Бәлки, бардыр. Ләкин миңа мәгълүм түгел. Шулай туры килүнең сәбәбе – мине консерватория тәмамлагач, 24 яшемдә армиягә алдылар; ә энеләрем үз вакытында хезмәт иттеләр. Ул вакытта, солдат хатлары алышканда, миңа – "картлач"ка бераз уңайсызрак иде. Нишлисең, шулай туры килде, шулай кирәк булгандыр. Ата-анабыз, Ватан-анабыз алдында хәрби бурычыбызны намус белән үтәдек...

Шуннан соң бер афоризм яздым:
Армиядән кайтучылар – дембельләр.
Армиядән качучылар – дебилләр.

Кемгәдер ошамаса, бераз тупасрак тоелса, гафу итегез. Ләкин бу – хакыйкать. Урыслар: лучше горькую правду, чем сладкую ложь, диләр. Ничек кенә атался да, армия армия инде: совет армиясеме, Россия армиясеме... Ул безне саклый, ә без, үз чиратыбызда, аны якларга, анда хезмәт итәргә тиеш. Бер акыл иясе болай дигән: "Не хочешь кормить свою армию, будешь кормить чужую..." Бу фикер белән килешми булмый. Халык әйтсә, хак әйтә...

Кирам САТИЕВ,
Татарстанның халык артисты,
виртуоз баянчы-гармунчы.

Атаклы артистның күпкырлы таланты язучылык шөгылендә дә ачылып ала. Аның сәнгатькә карашы һәм шул өлкәдә хезмәт казанган иҗатташлары турында берничә китап чыгаруы – моның ачык дәлиле. Шул ук вакытта 1649 гыйбарә (афоризм) авторы булуы күпләрне шаккаттыра. Менә шуларның берничәсе:

– Донорлар аз, кан эчүчеләр күп...

– Бүләк ике төрле була: биргәннәре – ошамый, ошаганын – бирмиләр...

– Артык ашыккан кешенең үз гомеренә бер машина җитә.

– Татарда – Тукай, урыста – Пушкин әкиятләр язып бөек булганнар. Бу фикеремне әкият дисәгез, мине дә алар янына бастырыгыз.







• • •

Хәзер барысы белән дә яхшы мөгамәләдә булу өчен, 4 теманы кузгату кирәкми: 1. Динне. 2. Сәясәтне. 3. Женси юнәлешеңне. 4. Вакцина ясату-ясатмауны.

• • •

– Микроволновкаң эшлиме?

– Сәгать кебек.

– Нигәдер ул җылытмый.

– Әйтәм ич, сәгать кебек дип.

• • •

Америка театрында А. Чеховның "Три сестры" спектаклен куйганнар. Аларны анда ак, сары, кара тәнле кызлар уйный.

• • •

Илледән соң гел розалар гына башлана: неврозлар, артрозлар, склерозлар, остеохондрозлар...

• • •

– Син нәрсә бүген бик канәгать кыяфәттә?

– Начальнигым көтмәгәндә мине эштә чакта тотты!

• • •

Forbes исемлеге бар, фатир өчен түләмәгәннәрнең подъезд ишегендәге исемлеге бар, әгәр дә сез бу исемлекләрдә юк икән, димәк, сез урта иҗтимагый сыйныфта саналасыз.

• • •

– Доктор, зинһар, ярдәм итегез! Күз алдымда әллә нинди яшел бөҗәләр әйләнеп тора!

– Ә үзегез нинди төс күрергә теләр идегез?

• • •

– Ни өчен хатын-кыз эшләмәгәндә, ул – өйдә хуҗабикә? Ә ир кеше эшләмәсә, ул – эшсез?

• • •

Ике таныш сөйләшә:

– Минем хатынның бернинди сәләте юк.


– Ә минекеннән бөтенесен көтәргә мөмкин...





ЧАЯН ШИФАХӘНӘСЕ

– Доктор, миндә коронавирус бугай. Миңа тест ясарга мөмкинме?
– Сез түрәме?
– Юк.
– Депутатмы?
– Юк!
– Бәлки җырчы йә артисттыр?
– Юк инде, юк!
– Алайса, җанкисәгем, тестсыз да күреп торам – сезгә бары тик салкын тигән!


Александр АЛЁШИН



Шамил ХӘЛИЛУЛЛОВ


Валерий ТАРАСЕНКО

Илья СУСЛОВ

Инҗенер фикере

Линейкин менә дигән инженер, белемле һәм бик сак кеше иде. Бөтен нәрсәгә дә фән күзлеге аша гына карарга өйрәнгән. Менә хәзер дә ул эш урынында утырган килеш, чираттагы тапкыр смартфонда яңа хәбәр укып утыра: "Вакцинация ярдәмендә америкалылар кеше канына чиплар кертәләр! Бу – гади кешеләргә хәбәр ителми торган халыкара сүз куешу!"

Бер сәгать элек эштә вакцина ясый башладылар. Табиблар килде. Халык чиратка басты. И ахмаклар! Күпме беркатлы надан икән тирә-юньдә! Ә Линейкин андыйлардан түгел. Аны мондый нәрсәләргә тартып та кертеп булмый. Ул өстәл тартмасын ачты һәм аннан "Шомлы планнар" дип язылган серле папкасын тартып чыгарды. Чәйнеген тоташтырып, өстәлгә бер кап зефир ачып куйды һәм "Иммунитетны күтәрү өчен, киптерелгән зефир ашарга кирәк" дип укыды.

Зефирны күралмавына карамастан, Линейкин аны кимерергә тотынды. Иң мөһиме – системага каршы эш итү.

«Баш миенә тәэсир итүче спутниклардан саклану өчен, фольгадан башлык ясарга кирәк".

Линейкин өстәленең аскы тартмасында яткан ялтыравыклы башлыкны алып киде.

Бер сәгатьтән ул үзе янына фикердәшләре – бригадир Солидолов, бухгалтер Дефицитова һәм сакчы Пистолетовны чакырып алды.

– Нәрсә, глобалистлар хәйләсенә бирештегезме? Кадаттыгызмы? – дип, кырыс кына сорады ул дусларыннан.

Барысы да фольга башлыкларын чыгардылар һәм башларына киделәр.

– Юк, нәрсә син!

– Нинди яңалыклар бар? – дип, Линейкин көрәштәшләренә карап куйды.

– Менә, – диде шаттавыш белән Дефицитова һәм телефонын чыгарды. – Дус хатынымның ахирәте күршесенең дустыннан хәбәр алган: зефирда биологик яктан эшкәртелгән микрочиплар бар икән!

Эльвира ДЫШАЕВА



Сергей АНДРИАНОВ



Линейкин урындыгыннан егылып төшә язды. Аның аяклары калтырана башлады.

– Нәрсә?! Төгәл мәгълүматмы бу?.. – дип сорады ул тетрәнеп.

– Төп-төгәл, – дип кисте Дефицитова. – Миңа текстны рәсем итеп җибәргәннәр, махсус органнар очына чыга алмасын өчен.

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты.

– Бүгенгә җитте! Сау булыгыз, дуслар. Таралышсагыз була, – диде күңелсезләнеп киткән Линейкин. Дөнья шатлыгын һәм яктысын югалтты.

«Барысы да юкка...» – дип уйлап куйды ул һәм эштән иртәрәк китәргә булды. Гадәт буенча, серле папкасын алып ишеккә таба юнәлде. Кинәт янәшәдә килде-китте сүзләре белән теңкәгә тиеп интектергән завхоз Стаканов пәйда булды.

Бу юлы да ул сәер шаяртулары белән Линейкинга бәйләнә башлады.

– Стаканов! Бар, кайтып йокла, айныгач сөйләрсең! Болай да баш каткан чак...

Подъездының эскәмиясенә җитү белән, Линейкин тагын папкасын ачты: "Иммунитет вакцинадан шәбрәк", "Прививкадан хыянәтләр килеп чыга"...

– Нәрсә ул кулыгызда, Линейкин, карыймчы? – арттан участковый Карауловның кырыс тавышы ишетелде.

Линейкин бер мәлгә югалып калды, ләкин бөтен ихтыяр көчен җыеп, папканы Карауловка сузды.

– Менә, шушында эскәмиядә таптым, – диде ул. – Мәктәп балалары пандемия вакытында иминлек турында доклад әзерләгәннәр, күрәсең. Интернеттан теләсә нинди ахмаклыклар җыйганнар. Шуңа ышанучы кешеләре дә табыла бит! Ярый, миңа китәргә кирәк, вакцинациягә җыенган идем...

Линейкин киң адымнар белән поликлиникага таба атлады. Тик фольга башлыгын салып атмады. Кем белә бит дөнья хәлләрен...



Анастасия ВАСИЛЬЕВА

Нәҗип КОТЫЕВ

КУАР КОТ СОРЫЙЛАР

Карт кеше инде мин. Мәчет карты диләрме?.. Намазыние... Атна саен мунча дигәндәй. Рәхәт бит, тәңгә, җанга сихәт өстәү! Тик менә дөньялар үзгәрде бит әле, элеккечә дә, без дигәнчә дә түгел... Мунчага керү рәвешләре дә үзгәрде.

– Бабай, куар котың бармы? – диләр.

– Бар, – мин әйтәм, – нишләп булмасын!

– Күрсәт! – дигәч, бераз каушап калдым, чөнки хәзер чынлап та кот куарлык кынадыр инде ул. Исемен дә тапканнар бит! Заманча исемдер инде. Мин үзем татарча гына уйлагач, сүзләрнең нигезен гел туган телемнән эзләп карыйм. Монысы – кот куярлык микән, кот куарлык микән инде? Теге елларда авылдан килгән генә мәлләр иде, туже шундыйрак яңа сүз белән бер "сандугач баласы" куар котымны барлаган иде... Анысы турында да озак кына уйланган идем. Урысчам да чамалы гына бит инде. Ул чакта күрсәт дип, артык кыстамадылар, ә бүген кот куарыңны күрсәтмәсәң, мунчага да кертмиләр булып чыкты. Вәйт, заман! Вәйт, әкәмәт! Кот куар диме? Кот куяр дип, ул кадәр үк коточкыч та түгел әле ул... Тик нигә аны касса янында ук күрсәтергә ди. Мунчага кергәч, үзегез кереп карарсыз, дигән идем. Тагы справка сорый башладылар, психик авыру түгеллегемә диме? Аптыраплар калдым. Менә, сез үзегез минем урында булсагыз, нишләр идегез? Мөселман кешесе өчен бигрәкләр сәер тоела инде боларның таләбе. Әйттем аптырагач: карчыгымнан башка беркемгә дә күрсәтмим, дип. Болай буласын белгән булсам, бергә-бергә килгән булыр идек анысы. Бүген ирләр көне дигәч, үзем генә килгән идем шул.

– Кертегез, – мин әйтәм, – кайтып карчыкны алып килгәнче, мунчагыз ябыла бит. Кертмиләр. Гел шул "куар кот"ны кабатлап тик торалар. Кереп, юынып-арыланып чыккач күрсәтермен дип тә карадым, барыбер кертмәделәр. Бер каен себеркесе, бер имән себеркесе салынган зур кабымны күтәреп, автобус тукталышына таба кыяклыйм. Автобуска килеп керүгә, Гарифулла кордаш очрады. Үч иткәндәй ул да:

– Ник чабынмадың соң? – ди.

– Кертмәделәр, – мин әйтәм, – теге нине күрсәтүне таләп итәләр...

– Ә-ә миннән дә сорадылар аны, – ди бу.

– Күрсәттеңме соң? – дим.

Тешсез авызын гына ера:

– Кая инде, мин бит нитмәдем нине. Кечкенәдән барыбызны ниттеләр лә... Тагын бер нитсәләр, бездән ни генә кала соң инде?

– Әйе шул, – дим, – бер киселгәнне тагын да кисәргә тырышалар. Шул киселгәнме-юкмы, дип, тикшерергә генә булганнардыр, бәлки. Тик тагы кисәргә булса, ни генә кала инде аннан: кот куярлыгы түгел, кот куарлыгы да калмый.

Автобус минем тукталышка кайтып җиткәндә, караңгы төшкән иде инде. Жилой массивның коточарлык куеннарыннан песи сыман гына уздым. Монда да үзләренә кирәкне таләп итүчеләр буа буарлык. Мунчага түлисе өч йөз сум салынган кесәне дә, киселгәнемнең исәнлеген капшап карадым да, барыбер артык сөенмәдем. Ник дисәң, теге яңа сүзнең эчке мәгънәсенә төшенеп җиткәнем юк шикелле тоелды: куар кот, кот куар, кот куяр, ягъни җан куяр була бит инде ул... Һай, замана! Теге мунчачылар ни эшләмәкче иделәр икән соң минем куар котым белән?

Алай да, алдагы атнада тагын барып карыйм әле.

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Маркет

Бугульмин

Ял

16+



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 11 (1912) ноябрь 2021

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://pqdpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.


«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 02.11.2021 ел.
Тираж – 4019 Заказ Е-3503

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Аяктагы чәнти бармак нәрсәгә кирәк?

2. Юлда туган бәхәсләрдә үзеңне ничек зыялырак итеп тотарга?

3. Чын ялган ниндирәк сүздән башлана?

4. Әйбәт мөнәсәбәтне ничегрәк сакларга?

5. "Уңышсыз очрашу" дигән мәгънә нәрсәне аңлата?

6. Нәрсә ул чипсы?

7. Эш һәм хезмәт – бер үк нәрсәме?

ҖАВАПЛАР

1. Өйдәге барлык җиһазлар да урынындамы икәнен белү өчен. 2. Бейсбол тәпәчен машинадан ыргыт һәм аның урынына гольф уйный торган тимер клюшка куй. 3. "Син, әлбәттә, миңа ышанмыйсың, ләкин..." 4. Хатын-кыздан – үткән тормышын, ә ир-аттан киләчәген сорамау. 5. Хатын-кыз янына бер букет тотып килү, киткәндә икенчесе белән китү. 6. Бер данә бәрәңгене бер килограмм бәясеннән сату. 7. Алай ук түгел. Эштән кеше тиешлесен алмый, ә хезмәттән – лаеклысын.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 10 нчы санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
Т. НУРГАЛИЕВ (Казан),
А. САФИУЛЛИН (Алабуга).
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Урта Тигәнәле),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),

Җиңүчебез – Алабугадан

Атлас САФИУЛЛИН!

СӘЕР КЕШЕЛӘР

Виктор ФЁДОРОВ



Илдар НӘФИЕВ



Валентин ДРУЖИНИН



Игорь КИЙКО





